ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2026 ел Баулы шәһәре №71

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр Планын раслау турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законы, техник яктан җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2023 елның 22 сентябрендәге 921-ст номерлы боерыгы белән расланган һәм гамәлгә кертелгән, Россия Федерациясе Милли стандартының ГОСТ Р 22.3.22-2023 «Гадәттән тыш хәлләрдә куркынычсызлык. Муниципаль берәмлек территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планы. Эшләү тәртибе. Эчтәлеккә һәм бизәүгә таләпләр» 4.8 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча кушымтада бирелә торган гамәлләр Планын (алга таба - План) расларга.

2. «Баулы муниципаль районы гражданнарны яклау идарәсе» МКУ җитәкчесенә Планны Баулы муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләренә һәм авыл җирлекләре башлыкларына җиткерүне оештырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.Л. Бакиров